| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЭБАЛАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 16 нчы сентябре Ябалак авылы № 106

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында» гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 маддәсе,Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның 25 мартындагы 23нче законының 12 маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Ябалак авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Ябалак авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

« Сез, 2020 елда Ябалак авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән т үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән килешәсезме».Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:*

- урамдагы яктырткычларны ремонтлау,моның өчен материаллар сатып алу;

- чишмәләрне төзекләндерү моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлегендә торак пунктлардагы тиешле һәм тиеш булмаган чүплекләр территорияләрен чистарту;

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

-юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г)  ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:*

-зиратларны чистарту һәм төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында һәм Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмати– телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http:/ ebalak-kaybici.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Карар рәсми рәвештә халыкка җиткергәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.